**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2022 елның 5 мае** **29 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне( «Орехов куст» коттедж комплексы) планлаштыру проектынраслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне( «Орехов куст» коттедж комплексы) планлаштыру проекты буенча 2022 елның 25 апрелендәге ачык тыңлауларның беркетмәсен һәм 2022 елның 25 апрелендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәсе бәяләмәсен карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегендә кадастр номеры 16:24:170301:775 булган җир кишәрлеге биләгән территорияне( «Орехов куст» коттедж комплексы) планлаштыру проектын расларга (Кушымта ).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

. 3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш шәһәренең җирдән файдалану, экологик иминлек һәм төзекләндерү мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районының**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф.Зарипов**